**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ**

423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17 нчейорт.Тел.3-02-22.Факс 3-13-44

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел. 3-02-22. Факс 3-13-44

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
04.10.2019

КАРАР
ПР-217

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ «АДАЙ БАШЛАНГЫЧ МӘКТӘП – БАЛАЛАР БАКЧАСЫ» БЕЛЕМ БИРҮ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ « КҮҖӘКӘ ТӨП ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ МӘКТӘБЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕНЕҢ СТРУКТУР БҮЛЕКЧӘСЕН БЕТЕРҮ ТУРЫНДА

"Россия Федерациясендә мәгариф турында" 29.12.2012 ел, № 273-ФЗ санлы Федераль закон нигезендә, 2019 нчы елның 1 нче октябрендә кабул ителгән 20 нче санлы бәяләмәсенә туры китереп, Актаныш муниципаль районы муниципаль белем бирү оешмасын үзгәртеп кору яки бетерү турында карар кабул итү нәтиҗәләрен бәяләү буенча комиссия, Күҗәкә авыл җирлегендә яшәүчеләр җыены фикерен 20.09.2019 исәпкә алып

**КАРАР БИРӘМ:**

1.Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Адай башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» белем бирү учреждениесе «Күҗәкә төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениясенең структур бүлекчәсен 07.10.2019 елдан бетерү.

2.Бетерелә торган белем бирү учреждениесе директоры Г.Ф. Газетдиновага:
-Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы «Күҗәкә төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе уставына үзгәрешләр проектын әзерләргә;

- хезмәт законнары нигезендә ликвидацияләнгән мәгариф учреждениесе штатларын кыскарту процедурасын үткәрүне тәэмин итәргә;

- Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының «Адай башлангыч мәктәп – балалар бакчасы» белем бирү учреждениесе «Күҗәкә төп гомуми белем бирү мәктәбе» муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесенең структур бүлекчәсен закон белән билгеләнгән тәртиптә бетерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы Л. Ф. Нурлыева